Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш.,Совет майданы, 27

тел. 3-16-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района
Республики Татарстан
Совет города Арск
422000, г. Арск, площадь Советская, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

**Арча шәһәр Советы карары**

**« 28 » декабрь 2015 ел** **№ 20**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә депутат таләбен (тәкъдимен) кертү һәм карау тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына туры китереп, Арча шәһәр Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре муниципаль берәмлегендә депутат таләбен (тәкъдимен) кертү һәм карау тәртибе турында" нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары Р. Р. Мамаделеевага йөкләргә.

Арча шәһәре муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г. Нуриев

«Совет города Арск»

Кушымта

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә депутат соравын (тәкъдимен) кертү һәм карау тәртибе турында» нигезләмә**

1 ст. Депутат таләбе

1.1. Депутат гарызнамәсе (алга таба - тәкъдим) белән «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының аерым органнарына, учреждениеләренә, предприятиеләренә, оешмаларына яки вазыйфаи затларына депутатның (депутатлар төркеменең) вәкиллекле орган компетенциясендә булган теге яки бу мәсьәлә буенча мәгълүмат бирү тәкъдиме (таләбе) таныла.

1.2. Сорауга җавап вәкиллекле органга юнәлтелә. Депутат запросына язма җавап рәислек итүче тарафыннан Арча шәһәре Советының чираттагы утырышында игълан ителә яки депутатларга бүтән юл белән җиткерелә.

2 ст. Депутат таләбен рәсмиләштерү

2.1. Депутат таләбе әлеге карарга беркетелгән язма формада Арча шәһәре Советы бланкында кертелә һәм депутат – гарызнамәнең авторы (авторлары) тарафыннан имзалана.

2.2. Депутат таләбе бланкында булырга тиеш:

-сорау реквизитлары (дата, чыгыш номеры);

- барлык реквизитлар күрсәтелгән адресатның исеме (ФИО, вазыйфасы, учреждение, предприятие исеме, адресы һ. б.);
- депутат таләбе предметы;
- депутат (депутатлар)имзасы;
- Арча шәһәр Советы утырышында депутат таләбен карау датасы турында мәгълүмат.

3 ст. Депутат таләбенә җавап бирү

3.1. Депутат таләбен юллаган вазыйфаи зат аны алганнан соң 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, язма рәвештә гарызнамәнең асылы буенча тулы аргументлы җавап бирергә тиеш.

4.2. Депутат таләбен юллаган вазифаи зат яки аның вазыйфаларын вакытлыча башкаручы зат тарафыннан җавап имзаланырга тиеш.

4.3. Депутат үтенече белән бәйле рәвештә өстәмә тикшерү үткәрү яки сорау җибәрелгән вазифаи зат, аны язмача формада алганнан соң, 5 көнлек календарь срогында бу хакта Арча шәһәре Советы хәбәр итәргә тиеш. Шул ук вакытта җавап срогы 15 календарь көннән дә артмаска мөмкин.

4.4. Депутат таләбенең үтәлешен «Арча шәһәре»муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары контрольдә тота.

4.5. Депутат үтенече белән мөрәҗәгать иткән Депутат аның соравына алган җаваптан канәгатьлек яки канәгатьсезлек белдерергә хокуклы.

4.6. Арча шәһәре Советы карары буенча депутат таләбе һәм җавап массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга мөмкин.

Кушымта

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Арча шәһәре муниципаль берәмлеге
422000, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-16-25

---

«____»____________ 20___ел №_____

ДЕПУТАТ ТАЛӘБЕ

_____________ ______________________
(имза) (депутатның ФИАи)

ТР КоАП 2.6 статьясы нигезендә муниципаль хокукый актларны үтәмәгән өчен административ җаваплылык каралган